ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УРМАНЧЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ленина, д.5, п.Зверосовхоза,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422186

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УРМАНЧЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Ленин ур., 5 нче йорт, Җәнлек совхозы поселогы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422186

тел.(факс): (85563) 2-12-50; e-mail: Urman.Mam@tatar.ru, www:mamadush.tatarstan.ru

Постановление | Карар

“22”декабря 2017 г. | № 67

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге территориясендә көнкүрештә кулланылган һәм яраксызга әйләнгән тererекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары исемлеге турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы, «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль законнарга таянып, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 3 сентябрендәге 681 номерлы карары белән расланган «Яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү, аларны тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру, гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләренең 8 пункты, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Урманчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Әлеге карарга кушымта булып килүче Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге территориясендә көнкүрештә кулланылган һәм яраксызга әйләнгән тererекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары исемлеген расларга.

2. Эшкәртелгән терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары исемлеге турында мәгълүматны урнаштыру түбәндәгечә башкарыла дип билгеләргә:

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлегенең түбәндәге адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында:

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Женлек сохозы авылы: , Ленин урамы 5 –авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы; Ленин ур., 4а йорт –СДК бинасы; Ленин ур., 6А–КБО бинасы;

2. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы Кама урман хуҗалыгы авылы: Үзәк ур., 18а –почта бинасы

3. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Яңа поселогы .: Садовая ур., 20А-авыл клубы бинасы

4. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Сотово авылы: Молодежная ур., 28а, китапханә бинасы

5. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Берсут авылы: Яр буе урамы 24А, почта бинасы

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында http://mamadysh.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук кулланылган һәм яраксызга әйләнгән теререкөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннарында урнаштырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль
районы
Урманчы авыл җирлеге башлыгы /А.Я.Ильин/

Кушымта
22.12. 2017 ел, № 67
карарына
Урманчы авылы
җирлеге
Мамадыш муниципаль районы
Татарстан Республикасы

**Исемлек**

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары**

| № | **Кулланылган сымап лампаларын беренчел җыю һәм урнаштыру урыны адресы** |
|---|---|
| 1. | 422186, Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы Кама урман хуҗалыгы авылы ,Заводская ур. ,34 |